# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№12 (736) 24 июнь 2021 ел (1442, Зөлкагъдә) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


*2021 ел - Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы*

## ТИЗДӘН – ОЛЫ БӘЙРӘМ



20 июльдә, зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә, мөселманнар Корбан бәйрәмен билгеләп үтәчәк. Бу уңайдан Татарстанның барлык мәчетләрендә Корбан гаете намазын кояш чыгып 30 минут узгач уку тәкъдим ителә. (Мисал өчен, 20 июль көнне кояш башкалабыз Казанда 03.27 сәгатьтә, Актанышта 03.07 сәгатьтә, Иске Чүпрәледә 03.39 сәгатьтә чыга. Шуңа кояш чыгу вакытларына игътибарлы булу сорала!). Башкала мәчетләрендә корбан гаете түбәндәге тәртиптә үтәчәк:

**02.30 – иртәнге намаз;**
**02.45-03.30 – Коръән укылу;**
**03.30-04.00 – гает вәгазе укылу;**
**04.00 – гает намазын уку;**
**04.05 – гарәп телендә хөтбә, Коръән укып дога кылу.**
**04.30 – корбан чала башлау.**

Казан шәһәрендә корбан чалу 16 урында башкарылачак. Республиканың башка зур шәһәрләрендә махсус урыннар мөхтәсибәт белән килештерелә. Мәчетләрдә бәйрәм намазлары, шулай ук корбан чалу гамәлләре коронавирус инфекциясе таралуны булдырмый калу чараларын күреп үткәреләчәк.

Корбан нисабының күләме – 595 грамм көмеш бәясенә тиң, бу 36 мең сум дигән сүз. Россия Үзәк банкы мәгълүматы буенча, 19 июнь көненә 1 грамм көмеш бәясе 61,27 сум тора.

Гарәфә көнендә (19нчы июльдә) иртәнге намаздан башлап, зөлхиҗҗә аеның 13нче көнендәге икенде намазын да (23нче июль) кертеп, егерме өч фарыз намазның һәркайсыннан соң сәлам биргәч, Аллаһы Тәгаләне олылап, аны данлап, өч мәртәбә: "Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү вәллааһү әкбәр. Аллааһү әкбәр вә лилләәһил-хәмд" дип тәкбир әйтү мәҗбүри була (хатын-кызлар тәкбирне эчтән әйтә). Бу – Тәшрикъ көннәре дип атала. Имам вә җәмәгать белән намаз укыганда тәкбирнең вәҗиб булуының мәгънәсе – адәм балалары Җир йөзенә яшәр өчен яратылды, адәм каны коелмасын, хайван каны гына коелсын дип сөенечтән тәкбир әйтүдәдер.

*(ТР МДН хәбәрләреннән)*

## НИ ЧӘЧСӘҢ, ШУНЫ УРЫРСЫҢ



Шәригать чигеннән чыгып ялкау булу һәм нәфес теләге артыннан йөрү адәм баласына авыру китерер, табигатен бозар һәм фәкыйрьләндерер. Шуның өчен беркайчан да эшсез тормагыз, ялкау һәм шөһрәт әсире булмагыз. Акылыгызны буш вә эшсез асрамагыз. Дөньяда яшәгән көннәрегездә ахирәттә файдасы булачак гамәлләргә игътибарсызлык күрсәтмәгез. Яхшы белегез ки, дөньяда тузан кадәр изгелек кылган кеше ахирәттә яхшы бүләк күрер, ә тузан кадәр начар гамәл кылган кеше, ахирәттә каты җәза күрер. Һәркемнең гамәле ахирәттә тышка чыгар һәм һәр гамәлнең җәзасы каршы килеп алыр. Шуның өчен вафат булганчыга хәтле файдалы гамәлләр кылыр өчен һәм артыгызда яхшы бер исем калдырыр өчен тырышыгыз. Чөнки адәм баласы вафат булыр, ләкин яхшы исеме вафат булмас, мәңге калыр.

**Риза ФӘХРЕДДИН** *("Әхлак гыйлеме"ннән)*

## ИМАМ-МӨХТӘСИБ БИЛГЕЛӘНДЕ



10 июнь көнне Чаллы шәһәре мөхтәсибәтендә имам-мөхтәсиб сайлау җыелышы булды. Мәҗлес кунаклары булып Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров һәм Чаллы шәһәре башкарма комитетының җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге башлыгы Рөстәм Галиуллин килде. Чара Коръән укып һәм дога кылып башланып китте. Беренче булып Әлфәс хәзрәт Гайфуллин чыгыш ясады. Үзенең чыгышында ул имамнарны 2017-2020 еллар эчендә Чаллы мөхтәсибәте тарафыннан башкарылган эшчәнлек белән кыскача таныштырып үтте. Аннан соң "Сөембикә" мәчете имам-хатыйбы Рәис хәзрәт мөхтәсибәтнең 4 еллык финанс эшчәнлегенә хисап ясады. Әйтелеп киткән хисаплар имамнар тарафыннан бертавыштан канәгатьләнерлек дип кабул ителгәннән соң, Равил хәзрәт Зөфәров мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның Чаллы мөхтәсибәтенең имам-мөхтәсиб вазыйфасына Әлфәс хәзрәтне тәкъдим иткән хатын укып үтте. Аны имамнар бертавыштан кабул итте һәм Әлфәс хәзрәткә янә имам-мөхтәсиб шәһадәтнамәсе тапшырылды. Соңрак мөхтәсибәт шурасы һәм ревизия комиссиясе әгъзалары составы кабул ителде. Мәҗлес Әлфәс хәзрәтнең, ышаныч белдергәннәре өчен, Чаллы имамнарына рәхмәт сүзләре һәм Рөстәм Рафик улының имам-мөхтәсибне тәбрикләве белән тәмамланды.

Җыелыштан соң имам-мөхтәсиб урынбасары Фоат хәзрәт Мөхәммәтовны 75 яшьлек юбилее белән котлау булды.

**Нияз ГАЗИЗОВ**

# КОРБАН ГАЕТЕ

**Барча галәмнәрне юктан бар кылучы, шул галәмнәрне тәрбия кылып һәм Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләндереп торучы Аллаһыга (сөбханәһү вә тәгалә) хәмде-сәнәләр, мактау-догаларыбыз, безне хак юлга күндерүче, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага (с.г.в.) күңелләребезнең түреннән чыккан салават шәрифәләребез булса иде. Барчаларыбызга да Аллаһының (сөбханәһү вә тәгалә) сәламнәре, рәхмәтләре һәм дә бәрәкәтләре булса иде.**

Корбан гаете, ягъни корбан бәйрәме көнендә мөселманнар корбаннар чалалар, чалган корбаннарын якыннарына, мохтаҗларга өләшәләр, туганлык хисләрен ныгыталар, мохтаҗларның күңелләрен күрәләр, җәмгыятьтә тынычлык урнашуны, җәмгыятьнең алга барышын тәэмин итәләр һәм шулай итеп Аллаһы Тәгаләгә якынаялар. Корбан - якынаю дигәнне аңлата. Бу көн турында пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Аллаһы Тәгалә каршында көннәрнең иң бөеге – корбан чала торган көн» ( Әбү Давыд, 18/1765).

Аллаһы Тәгалә укыган намазларыбызны, чалган корбаннарыбызны һәм кылган барлык изге гамәлләребезне кабуллардан кылсын.

Аллаһы Тәгалә бөтен мәхлукларны һәм шул исәптән кешеләрне Исламда гына, ягъни шәригать кануннарына буйсынган хәлдә генә яши торган итеп ярата. Аллаһы (сөбханәһү вә тәгалә) әйтә: «Кеше белән җенне фәкать үземә генә гыйбадәт кылсыннар өчен халык кылдым» (51.56).

Шәригать кануннарына буйсынып яшәгәндә кешенең һәр гамәле гыйбадәт була, һәр гамәле аны Раббысына якынайта. Бүгенге көндә безнең корбаннар чалуыбыз фәкать безнең шәригать кануннарына буйсынуыбызны һәм Аллаһы Тәгаләгә якынаерга омтылуыбызны күрсәтә торган күркәм гамәлләрдән булып тора.

Шәригать кануннарына буйсынмаган халыклар юкка чыгалар, бетәләр. Бу - Адәм галәйһиссәламнән бүгенге көнгә кадәр килә торган тарихи хакыйк. Халыклар, әлбәттә, барысы да бер көн эчендә һәм бер үк сәбәпләр белән юкка чыкмыйлар. Коръәндә кайбер халыкларның ничек һәлак булулары безгә гыйбрәт һәм мисал итеп китерелә. Бүгенге көндә Европада сугыш булмаганга 76 ел. Без ел да җиңү көнен бәйрәм итеп зурлап уздырабыз. Күпләр сугышта җиңелгән халыкларның бездән яхшырак яшәгәненә кызыга. Тормышлары бай, кануннары гадел. Әмма нигезе динсезлеккә корылган Европа әхлаксызлык упкынына кереп үлеп бетеп бара. Нигәдер анысын күрергә теләмиләр. Ә без, җиңгән халык, ничек яшибез соң? Без сугыш ачысын татыган, күпне күргән халык буларак, берөзлексез «Сугыш булмасын», дип дога кылабыз. Безгә каршы яу чапмыйлар, безне үтермиләр, таламыйлар. Шулай булса да без дә Европа артыннан, балга төшкән чебен кебек, дөнья ләззәтенә батып, акны карадан аермыйча әҗәлебезгә якынаябыз. Әйе, безнең балаларыбызны үтермиләр, әмма без үзебез теләсә нинди дошманнан да остарак итеп бу эшне үзебез башкарабыз. Соңгы еллардагы мәгълүматларга караганда, Россиядә бер көнгә 22 000 аборт ясала, ягъни бу бер елга 8 млн.га кадәр аборт ясала дигән сүз. Икенче Бөек Ватан сугышында РСФСРдан 4 елга 14 млн (СССРдан 20 млн) кеше һәлак булган, ә бүген абортлар белән 4 елга 32 млн кеше дөнья яктысын да күрә алмыйча үтерелә. Димәк, абортларның фаҗигасе икенче бөек ватан сугышыннан да куркынычрак. Дошман кулыннан һәлак булуны ничектер аңлап буладыр кебек, ә менә ата-ананың үз балаларын үтерүләрен аек акыл белән һич кенә дә аңлап һәм аңлатып булмый. Ә безне, мөселманнарны, корбан чалган өчен вәхшилектә гаепләргә тырышалар. Абортлар, үтерешләр, сугышлар дөнья малы өмет итеп башкарылсалар, без корбаннарыбызны дөнья малларын сарыф итеп, фәкать Аллаһы ризалыгын өмет итеп чалабыз.

Аллаһы (сөбханәһү вә тәгалә) Коръәндә әйтә: «Ул корбанга чалынган хайваннарның ите дә, каны да Аллаһка ирешми, Аллаһка фәкать сезнең тәкъвалыгыгыз гына ирешә» (22.37).

Без, мөселманнар, кан коймыйбыз, без кан коюга каршы. Шушы аятьтә әйтелгәнчә, без фәкать Аллаһы Тәгалә безгә хәләл иткән хайваннарны гына корбан итеп чалабыз, шул корбан ите белән үзебез сыйланабыз, туганнарны һәм мохтаҗларны сыйлыйбыз. Без бу эшне Аллаһы Тәгалә боерганга, буйсынып һәм гыйбадәт буларак башкарабыз. Кеше җирдә сынала. Аллаһы (сөбханәһү вә тәгалә) әйтә: «Ул үлемне һәм тереклекне халык кылды, йөкләмәләр йөкләп сезне сынамак өчен, кайсыларыгыз яхшырак гамәлле икәнлеген белмәк өчен, Ул һәрнәрсәдән өстен вә ярлыкаучы» (67.2).

Алда әйтеп кителгәнчә, кеше җирдә гыйбадәт кылу өчен халык кылына һәм ул үзенең ничек гыйбадәт кылуы белән сынала, ягъни җирдә сынау уза. Шул сынауны ничек узуына карап аның ахирәттәге мәңгелек тормышы билгеләнә. Иң зур сынау, әлбәттә, пәйгамбәрләргә була. Һәм Ибраһим галәйһиссәлам дә үзенең иң кадерле нәрсәсе белән, картлык көнендә генә күрергә насыйп булган бәгырь җимеше, газиз улы Исмәгыйль галәйһиссәламне корбан итү белән боерылып сынала. Ул Раббысының боерыгын үтәргә алына, әмма ахыр чиктә Исмәгыйль галәйһиссәлам куй белән алыштырыла һәм шуннан соң мөмкинлекләре булган мөселманнарга гает көнәрендә гает намазыннан соң корбан чалу вәҗиб гамәл булып йөкләтелә. Бу вакыйга тагын шунысы белән игътибарга лаек, ул кеше канын түгүнең катгый рәвештә тыелуын күрсәтә торган бер дәлил, бер боеру булып тора.

Аллаһы (сөбханәһү вә тәгалә) Ибраһим галәйһиссәламгә боерып Коръәндә әйтә: «Аллаһының, изге балаңны корбан итеп чал, дигән әмере, әлбәттә, зур һәм авыр сынаудыр» (37.106).

«Без аңа Исмәгыйль урынына корбан итеп бугазлар өчен Җәннәттән бер зур тәкә бирдек» (37.107).

Бу боеру Ибраһим галәйһиссәламгә генә түгел, бәлки бөтен кешелеккә боеру. Абортмы, балага дөрес тәрбия бирмичә әхлаксыз иттереп үстерүме, нинди генә рәвештә булуга карамастан, үз балаңны корбан итү тыела.

Без тормышта кешеләрнең зур шәхесләр турында «Ул үзен сәнгатькә корбан иткән, ул үзен спортка корбан иткән», дип әйткәннәрен ишетәбез һәм күпләр үзләренең балаларын шундый шәхесләргә охшатып тәрбияли, үзләренең Аллаһының коллары икәнлекләрен онытып, яисә белмиләр. Ә бу шәхесләрнең күбесенең тормышы әхлаксызлыкта узганы һәм тәмамланганы турында уйламаска тырышалар. Ата-ана иң элек үзенең дөнья ләззәтеннән мәхрүм калуыннан куркып аборт ясап балаларын корбан итсә, ә аннары исән-сау туган балаларның үзләрен дөнья малына, дөнья дәрәҗәсенә корбан итәләр. Шуннан соң без халыкның әхлаксызлыгына аптырыйбыз.

Безнең халык – мең ел дәүләт тоткан, бөтен дөнья белән идарә иткән халык. Аның 1100 еллык Ислам дине кабул итеп яшәгән, башка теләсә нинди халык кызыгырлык, көнләшерлек искиткеч гүзәл тарихы бар. Аның холкы-әхлагы Ислам дине белән формалашкан, сугарылган, тәрбияләнгән. Безнең балаларыбыз шушы гасырлар буе формалашкан тарихи кыйммәтләребезгә нигезләнеп үзебезнең милли тәрбиябездә, Ислам тәрбиясендә тәрбияләнергә тиешләр. Бүген безгә көчләп тагыла торган тәрбия – ул Европа тәрбиясе. Ә Европада бүген, алда әйтеп кителгәнчә, гаилә төшенчәсе юк дәрәҗәсендә, бер җенесле никахлар чәчәк ата, бала тумый. Бүгенге бала – безнең нәселебез, безне алмаштырырга тиешле буын, илнең, халыкның киләчәге. Бала тәрбияле булсын өчен беренче чиратта гаилә ныклы булырга, гаиләдә ата-ана үз вазыйфаларын тиешле рәвештә башкарырга тиеш. Бала тәрбияләүгә, гаилә мәсьәләсенә без аеруча нык игътибар итәргә тиешбез.

Бүген илдә 82% гаилә таркала, дәүләт кануннары нигезендә күпчелек очракта бала анасы белән кала һәм бала ана тәрбиясендә атага нәфрәт белән үсә. Күпме хатын-кыз «үзем генә картаям», дип куркып үзенә иптәшкә зинадан бала таба, аларның баласы да ата кешенең бар икәнен белмичә үсә. Балалар бакчаларында тәрбиячеләр булып, мәктәптә укытучылар булып хатын-кызлар эшлиләр. Бүгенге атасыз тәрбиянең нәтиҗәсе буларак ир бала өйләнеп, гаиләдә ир вазыйфасын башкара алмый, ә ир-ат күрми үскән кыз бала да кияүгә чыгып ир белән тора алмый, ягъни ир хатыны вазыйфасын башкара алмый. Хатын-кызлардан еш кына «бүген чын ирләр юк», дигән сүзләр ишетергә туры килә. Чын ирләр ирен санга сукмаган, яисә ирсез хатын-кызлар, яисә хатын эшләп тапканга риза булып яткан ирләр тәрбиясендә үсмиләр, бәлки алар ир ир булган һәм хатын хатын булган ныклы гаиләләрдә генә тәрбияләнәләр. Ир-атларны күпме генә тәнкыйтьләсәк тә халкыбыз: «Ирне ир иткән дә хатын, чир иткән дә хатын», ди. Димәк, ике якка да мәсьәләне дөрес аңлап хәл итәргә кирәк. Шулай да Аллаһы Тәгалә ир-атны өстенрәк итеп яраткан һәм без бу өстенлекне гамәлләребез белән расларга тиешбез. Ә бүген исә Татарстанда 2000нән артык ир декретный алып өйдә утыра. Бу ирләр белән дәүләт проблемасын да, милләт проблемасын да хәл итеп булмый инде. Халкыбыз дингә йөзе белән борылмаса, озакламый аның теле генә түгел, үзе дә калмаячак. Аның урынын башка, Аллаһы Тәгаләгә буйсынучан булган халык алачак. Аллаһы (сөбханәһү вә тәгалә) әйтә: «Әгәр сез Аллаһыга буйсынудан баш тартсагыз, сезнең урыныгызга башка затларны китерер ки, алар сездән хәерлерәк булырлар» (47.38).

*(Ахыры газетаның киләсе санында)*

**Рөстәм хәзрәт ШӘЙХЕВӘЛИЕВ,**
*Чаллының "Ак мәчет" имам-хатыйбы*

*СОРАУ-ҖАВАП*

Укучылардан килгән сорауларга шәригать белгече **Рәфыйк хәзрәт МИННӘХМӘТОВ** җавап бирә.

**Сорау.** Хөрмәтле редакция! Сорауларыбызга Рәфыйк хәзрәт Миннәхмәтов сезнең газета аша киңрәк җавап бирсә, бик рәхмәтле булыр идек.

*Илдар М.*

1. Әбү Хәнифә мәзһәбендә булмаган кешеләр дә һәм без сөннәт буенча гамәл кылабыз дип, бер мәзһәбне дә кабул итмәгән кешеләр дә, хәзрәтләр булмаган вакытта җәмәгать намазларында имам булып басарга яраталар. Шушы кешеләр имам булып басып, намазны Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча укысалар, укыган намазларга кимчелек килмиме? Шушы имамның һәм аңа оеп укучыларның укыган намазлары кабул буламы?

2. Имам булып баскан кеше фарыз намазны укыгач та урыныннан торып китү рөхсәт ителәме? Әллә тулысы белән намазны тәмам кылып, тәсбих әйтеп тәмамлау дөрес буламы?

**Җавап**. 1. Һәрбер акыллы бәлигъ мөселман намазда имам була ала. Чөнки намазның дөреслеге аның шартлары һәм фарызлары үтәлүгә бәйле. Имамлык олы әманәт булып тора, шуңа күрә имам итеп ышанычлы, әманәтле кешене кую яхшырак. Һава (фикһый мәзһәбләрне инкарь итүчеләр шулай ук һава әһелләре санала) һәм бидгать әһелләренең имам булуы мәкруһ. Әмма намазның фарызлары үтәлсә, ул намаз дөрес була, имамның үзе өчен дә, җәмәгать өчен дә. Мәхәлләнең уставында имам булмаган очракта кем аны алыштыра алуы турындагы тәртипләр язылган, һәм шул тәртипләр үтәлергә тиеш. Гыйбадәтләрнең кабул ителүе-ителмәвен бер Аллаһ үзе генә белә. Ә без инде аларны мөмкин кадәр Аллаһ һәм Аның илчесе кушкан рәвештә үтәргә тырышырга тиеш.

2. Намазда имам булган кеше фарыз намазын укып бетереп, сәлам догасын уку белән үк торып китсә дә рөхсәт ителә. Әмма сөннәткә туры китереп тәсбих-зикерләрен әйтеп, догаларын кылып китсә яхшырак. Гозер булмаганда имамга да, җәмәгатькә дә фарыз намазыннан соңгы сөннәт-нәфел гыйбадәтләрне үтәргә кирәк.

**ӘДӘБИ СҮЗ**

## БӘХЕТ

*Әлхәмдүлилләһ,*
*Эш-мәшәкатькә тулы*
*Янә озын көн килде.*
*Яңа көнне күрүләре*
*Бәхетнең үзе инде.*
*Саулык, шатлык, иминлекне,*
*Раббыбыз, бездән алма.*
*Хәвеф-хәтәр, казалардан*
*Җир-күгебезне сакла.*
*Теләкләрне дога аша*
*Хагыбызга юлласак,*
*Кулын сузып үтенгәнгә*
*Ул җавап бирми калмас.*
*Күңел күгегез балкысын,*
*Сөенеч вә шатлыктан.*
*Хак Тәгалә аермасын*
*Саулык дигән байлыктан.*
*Гомер үтә, сорап тормый,*
*Көннәрне айга ялгап.*
*Кемгә күпмеләр язгандыр,*
*Беребез белми ныклап.*
*Дөньябызның бар ямьнәре*
*Бөек Көчнең кодрәте.*
*Насыйп булсын безгә шуны*
*Аңлап яшәү куәте.*

***Фәнисә ФӘХРЕТДИНОВА,***
*Башкортостан, Кушнаренко районы, Әхмәт авылы*

## МОСАФИР

- Сәфәргә чыккан кеше үз шәһәренең йорты яныннан башлап, шәһәренә кайтып кергәнче яки бер шәһәрдә 15 көнгә кадәр торуны ният кылучы мосафир хөкемендә була.
- Әгәр мосафир бер шәһәрдә 15 көн торуны ният кылса, шул вакыттан алып мокыйм хөкемендә була, әгәр дә 15 көн тулганчы тагын сәфәргә чыкса, мосафир хөкемендә була.
- Мосафирның бер шәһәрдә 15 көн тору нияте булмыйча, эшләре чыгу сәбәпле яки берәр хәбәр көтү сәбәпле 15 көн кадәр шул шәһәрдә калса да, барыбер мосафир хөкемендә була.
- Ике шәһәрдә йорты булган кеше шул шәһәрләрнең кайсына гына барса да мосафир булмый. Әгәр дә ул шәһәрләрнең арасы йөз чакрым кадәр булса, бер йортыннан икенчесенә барганда мосафир хөкемендә була.
- Мосафирның өч өстенлеге бар:

1) мосафир кешегә өйлә, икенде һәм ястү намазларының фарызларын икешәр генә рәкәгать итеп кыскартып уку - вәҗиб;

2) читекләргә өч тәүлек тулганчы мәсех тарту дөрес була;

3) сәфәр вакытында Рамазан аетуры килсә, уразаны тотмыйча казага калдыру дөрес була.

- Мосафир дүрт рәкәгатьле сөннәт намазларын һәм өч рәкәгатьле ахшам һәм витр намазларын кыскартырга тиеш түгел.

## ЫШАНЫЧ, ӨМЕТ, ТӘВӘККӘЛЛӘҮ

Бервакыт диңгездә бик каты давыл чыгу сәбәпле, шактый күп кеше сәфәр кылган зур көймә су астына китә. Корабль һәлакәтеннән соң бердәнбер исән калган сәфәрчене дулкыннар кеше яшәми торган утрауга чыгарып ата. Ачы язмыш хәсрәтенең бөтен кыенлыгын яхшы аңлаганга күрә, бичара ир Аллаһтан ярдәм сорап, ихлас дога кыла башлый. Котылырга өметләнеп, ул көн саен офыкка бага, көтә, ләкин... инде байтак вакыт узуга карамастан, берни дә үзгәрми, ярдәм килми... Шулай да ир өметен өзми һәм Аллаһка ялваруын дәвам итә.

Көн артыннан көн үтә. Җил-яңгырдан ышыкланыр һәм төрле хайван-хәшәрәтләрдән сакланыр өчен кеше кәкре-чатаклы агач кисәкләреннән уртача зурлыктагы алачык төзеп куя. Тырышканнары әрәм булмый: сыеныр урынга әверелгән әлеге кечкенә торакта ул тынычлап ял итә, гыйбадәтен кыла.

Көннәрдән беркөнне ризык хәстәрләү эше белән йөргән чакта, ир-ат үзе төзегән алачык тирәсеннән ургылып төтен чыкканын күреп ала. Шунда йөгереп килүгә ул коточкыч хәлгә тап була: аның шактый озак һәм бик күп көч куеп төзегән газиз торагы дөрләп яна иде... Салкыннар башланыр алдыннан җылы торактан мәхрүм ителүе аркасында кеше күңелен төшенкелек һәм зур курку биләп алды. “Йә Аллаһ, ничек шулай булды соң әле бу?” – дип өзгәләнде ир-ат, ләкин әтисенең Аллаһның рәхмәтеннән беркайчан да өметеңне өзмә” дигән киңәшен исенә төшереп, күңеле сыкравына карамастан, ихлас догасы белән Раббысына мөрәҗәгать итте.

Караңгы төшкәч, кеше кара күмергә әйләнгән, әмма әле һаман төтенләп торган чатак-ботаклар артына яшеренеп йокларга ятты; таң атуга исә, нәкъ иртәнге намаз алдыннан нииндидер көчле тавыштан уянып китте. Житез генә аягына басып, ул диңгезгә күз салды һәм... утрауга таба якынаеп баручы бик зур көймәне күреп алды. Бу Котылу көймәсе иде! Шатлыклы, җылы күрешүдән соң кеше матрослардан: “Ни өчен сез юл юнәлешен үзгәртеп, шушы утрауга таба борылырга булдыгыз?” – дип сорый. Алар исә болай җавап бирә: “Без синең төтен сигналыңны күрдек...”.

Менә шулай – бер уйламаганда-көтмәгәндә – бәхетсезлек очрагы бу кеше өчен бәхетле котылуга сәбәп булды. Чыннан да, Аллаһ әмере белән тормыштагы ниндидер күңелсез вакыйга “Бәхет” дигән ишекнең ачкычы булып чыгарга мөмкин. Шуңа күрә бик авыр тоелган хәлдә дә өметне өзеп төшенкелеккә бирелергә ярамый. Безнең белән булган һәр хәлне Аллаһның Рәхмәте, хикмәтле планы дип кабул итәргә кирәк. Ни генә булса да, безнең өчен иң мөһим нәрсә ул – Аллаһның кадирлегенә ышаныч, Аның ярдәменә өмет һәм бөтен күңел белән Аңа тәвәккәлләү...

**Ришат хәзрәт КУРАМШИН** *әзерләде*

## КОЛАК САЛСАҢ, ҮКЕНМӘССЕҢ

* «Кулыңны үз муеныңа бәйләмә (саран булма); кулларыңны җәеп тә җибәрмә (артыгын юмартланма да). Ахырда (саран дип) сине ачуланырлар, (малыңны туздырып) син бичара хәлдә калырсың». («Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:29)

* «... алар сарыф иткәндә исраф кылмыйлар һәм саранланмыйлар, мондый чикләргә төшмичә уртача булалар...» («Фуркан / Аеручы», 25:67)

* «Алар күзгә күренмәгәннәргә ышана, намазларын дөрес итеп укый. Без биргән малларын Аллаһ юлында сарыф итә». («Әл-Бәкара / Сыер», 2:3)

* «Әй, мөэминнәр, җыйган малларыгызның иң затлыларын гына вә сезнең өчен җирдән чыгарганнарыбыздан (сәдака, хәер, зәкәт биреп, Аллаһ юлында) сарыф итегез. Күз йомып (чыраегызны сытып, җирәнеп кенә, теләр-теләмәс кенә) алырдай затсыз малны бүләккә бирмәгез (үзегезгә ошамаган, гамәлгә яраксыз мал хәергә бирелмәс). Белеп торыгыз, Аллаһ чиксез бай һәм мактауга лаек». («Әл-Бәкара / Сыер», 2:267)

* «Сез сөекле нәрсәләрегезне (мал-мөлкәт, сәдака, зәкәтләрегезне Аллаһ юлында) сарыф итмәсәгез, игелеккә ирешә алмассыз. Сез нәрсә сарыф иткәнегез-итмәгәнегезне дә Аллаһ белеп тора». («Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:92)

* «Әй, мөэминнәр, кешеләргә күрсәтер өчен генә сәдака-мал бирмәгез. Аллаһка, Ахирәт көненә ышанмаган кәфер кебек, хөсетлек, рия белән, кешене рәнҗетеп сәдака бирмәгез...» («Әл-Бәкара / Сыер», 2:264)

* «Сәдакаларыгызны ачык итеп бирсәгез, яхшы булыр. Сәдакаларыгызны фәкыйрьләргә яшертен бирсәгез, сезнең өчен тагын да хәерлерәк булыр. Шуңа күрә, Аллаһ гөнаһларыгызның бер өлешен ярлыкар. Сез ни генә эшләсәгез дә, Аллаһ барысыннан да хәбәрдар». («Әл-Бәкара / Сыер», 2:271)

## ИҢ ЯХШЫ СӘДАКА - СУ



Су - табигатьтә иң кадерле нәрсә. Аллаһ Сүбеханәһү үә Тәгалә Коръән Кәримдә: Аллаһу Тәгалә һәрнәрсәне сыеклыктан яраттыˮ, - диде. “Иң яхшы сәдака - су белән сугаруˮ, - дигән хәдиснең тарихы болай: Сәгыйть исемле бер кеше Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) янына килә һәм аңа сорау белән мөрәҗәгать итә: “Йә, Пәйгамбәр, әти-әнием исән вакытта мин аларга сәдака кыла идем, аларны тәрбияли идем. хәзер әнием вафат. Аңа нәрсә белән сәдака кылу хәерлерәк булыр?ˮ Пәйгамбәребез (с.г.в.) аңа: “Су беләнˮ, - дип җавап бирә. Гади кеше бу сүзләрне бер стакан су бирү дип аңлар иде. Ләкин сәхабәләр бик тирән фикер йөрткәннәр. Бу кеше Пәйгамбәрнең (с.г.в.) җавабын алгач, үз әнисе хөрмәтенә кое казыта һәм аңа әнисенең исемен куша. кеше шул коедан су алган саен Сәгыйтьнең анасына һәм аның үзенә дә сәдака, әҗер-саваплар булып тора. Шулай итеп, су бик яхшы сәдака булып тора.

**Габделхак хәзрәт САМАТОВ**

## ТЕЛ ҺӘМ ЙӨРӘК



Дауд галәйһис-сәлам хәзрәти Локманга әйткән:

- Бер бәрән суй да, аның тәнендәге ике иң яхшы өлешне миңа китер!

Хәзрәти Локман кушканнарны эшли һәм тел белән йөрәкне алып килә.

- Ә хәзер иң начар өлешләрен алып китер!

Хәзрәти Локман кабат тел белән йөрәк күтәреп килә. Дауд галәйһис-сәлам моның сәбәбен сорагач, ул болай ди:

- Әгәр йөрәк белән тел яхшы булсалар, бөтен тән яхшы булыр, ә инде алар начар икән, тән дә яхшы була алмас.

Ислам дине күрсәткән юл - күркәм тел белән яхшы гадәтләргә чакыру, начар, бозык эшләрдән үзеңне һәм телеңне тыю. Дөньяның матур, тормышның ямьле, ризыкның тәмле булуы, күршең белән тату яшәү, тәмле тел белән аралашу, тыныч дуслык, бер-береңә ярдәмле, рәхимле, шәфкатьле булу да шул телгә барып тоташа. Ислам шуны таләп итә.

## МИН ДӘ БЕР ХӘДИС

• Бер адәм үзе кешегә мәрхәмәтле булмаса, Аллаһы Тәгалә дә аңа карата мәрхәмәтле булмас.

• Мөэмин карендәшенә бер ел буе ачу тоту аның канын түккән кебек.

• Кем кешегә зарар ясый, Аллаһы Тәгалә аның үзенә дә зарар җибәрер. Кем кешегә мәшәкать һәм авырлык китерә, Аллаһы Тәгалә аның үзен дә шуңа дучар итәр.

• Холыксыз кеше үзен газапка салыр. Кайгысы күп булган кешенең тәне сәламәт булмас, үч һәм дәгъва белән мәшгуль булганнарның халык арасында кадере китәр, күздән төшәр.

• Кайгыларны, авыруны һәм сәдаканы яшерү – изгелек хәзинәсенә ия булу.

• Бәндәнең дине вә дөньясына файдасыз нәрсәләрне ташлавы – исламиятенең гүзәллегенә бәйле.

• Кеше арасын бозу өчен сүз йөртүдән сакланыгыз. Халык арасында юкны-барны сөйләмәгез. Сүз йөртү – бөек гөнаһ.

• Вафатыннан соң үкенмәгән кеше юк. Яхшы кешеләр дөньяда яхшылыкларын арттырмаганга үкенерләр, яман кешеләр ямалыктан тыелып тәүбә итмәгәннәренә үкенерләр.

• Кеше һәр ишеткәнен сөйләсә, гөнаһлы булу өчен шул җитә.

• Аз булса да житсә, сине юлдан яздырган күп малдан хәерлерәк.

• Ачу һәм көнчелек кешенең яхшылыкларын ут утынны ашаган кебек ашап бетерә.

• Авыруны дәвалау – тәкъдирдән, Аллаһның рөхсәте белән генә файда бирер.

• Яман холык белән саранлык мөэмин кешедә бергә җыелмас.

• Һәр ни кылсагыз Аллаһы ризалыгы өчен камил ихлас белән кылыгыз, ихлассыз кылган гамәлләрне Аллаһы Тәгалә кабул итмәс.

• Ялганнан сакланыгыз, чөнки ялган иманнан ерак.

*Балалар өчен*

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА**

## ТАТАР ӘЛИФБАСЫ

Намазлыкка басса әби,
Йөрибез шыпырт кына.
Комачауларга ярамый
Аңа намаз укырга.



Үзебез дә өйрәнербез,
Әби булышыр безгә.
Намаз уку – фарыз гамәл
Мөселман-мөэминнәргә.

*Саулыгым-байлыгым*

## УКРОП



Халык медицинасында укропның орлыкларын һәм үләнен элек-электән кулланганнар. Гипертония (югары кан басымы) авыруыннан укроп үләне төнәтмәсе яхшы булыша: 1 аш кашыгы киптереп ваклаган үләнгә 150-200 мл (1 стакан) су кайнатып салып, 15-20 минут төнәтеп сөзәләр. 1 стакан төнәтмәне көн дәвамында 3 мәртәбәгә бүлеп, ашарга ярты сәгать кала эчәләр.

Ризык эшкәртелү бозылганда, аппетитны яхшырту өчен, тын кысылудан һәм тын юллары авыруларыннан укроп орлыгын порошок рәвешендә дә, төнәтмә ясап та файдаланалар. Төнәтмәне 1:10 нисбәтендә ясыйлар (ягъни 1 өлешкә - 10 өлеш су). Мондый төнәтмә сидек кудыргыч бударак та яхшы. Укроп орлыгын какырык чыгаручы, үт бүленеп чыгуны көчәйтүче, ашказаны- эчәклек, бавыр, атеросклероз чирләреннән булышучы чара буларак та файдаланалар. Моның өчен 1 аш кашыгы укроп орлыгына 1 стакан кайнап торучы су коялар да, суынганчы төнәтәләр һәм шуннан соң сөзәләр. Көнгә 3 мәртәбә 1 әр аш кашыгы эчәләр.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нурыˮ дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нурыˮннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Бу санның тиражы: 1100**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга тапшырсагыз иде. “Ислам нурыˮның һәр саны кулдан-кулга күчеп, динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *
Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нурыˮ басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**24 июнь 16 сәг.**
**фактта 24 июнь 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**